МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.08.2024 Казан ш № 547

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 16 июлендәге 560 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2018 елның 16 июлендәге 560 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш

белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 20 октябрендәге 739 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге 484 номерлы, 2024 елның 14 мартындагы 170 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә – Министрлыкка караган учреждениеләрдә хезмәт законнары таләпләренең һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә бүлек компетенциясе чикләрендә ведомство контролен гамәлгә ашыруда катнашуны күздә тоткан әйдәп баручы киңәшче; коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы әйдәп баручы белгеч;»;

3.4 һәм 3.8 пунктларның көчен югалтуын танырга;

түбәндәге эчтәлекле $3.24^{2}$ пункт өстәргә:

«$3.24^{2}$. хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;».

| | | |
|---|---|---|
| Министр в.б. | | Н.В. Бутаева |